Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

23 июнь 2020 ел №379

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2009 елның 25 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасы турында»гы 367 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының 2019 елның 27 июнендәге Территориаль планлаштыру схемасына кертү проектын килештерү турында җыелма бәяләмәдә билгеләнгән искәрмәләрне җайга салу буенча килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе нигезендә,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2009 елның 25 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасы турында»гы 367 нче номерлы карарына (2013 елның 19 декабрендәге 349 нчы номерлы, 2017 елның 30 мартындагы 170 нче номерлы Әлмәт муниципаль районы Советы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар кушымтасы «Кереш» бүлегенең икенче абзацыннан соң түбәндәге эчтәлекле яңа абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасы проекты (үсеш программаларын гамәлгә ашыру өлешендә үзгәрешләр кертү) «Татинвестгражданпроект» ДУП 2017 елның 17 апрелендәге 8272 номерлы контракт нигезендә эшләнгән.

Эшләүгә нигез булып Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башлыгының (2016 елның 25 декабрендәге 7962 нче номерлы хат) һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мөрәҗәгате булды (2017 елның 10 апрелендәге 2072 нче номерлы хат).

П. 49 «Республика программалары һәм проектлары» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«49. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 21 февралендәге 134 нче номерлы карары белән (Министрлар Кабинетының 2017 елның 15 августындагы 577 нче номерлы карары редакциясендә) расланган Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы.»;

1.2. 2 нче бүлектә. «Әлмәт муниципаль районының территориаль планлаштыру чаралары исемлеге»:

2.1. таблицага «2009-2030 еллар чорына Әлмәт муниципаль районында гамәлгә ашырылган сәнәгать чаралары исемлеге» «Мероприятия һәм җирле әһәмияттәге объектлар» бүлегендә, башка «Металл булмаган минераль продуктлар производствосы» өлешенә түбәндәге эчтәлекле 15 нче пункт өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 15 | «Петровский руда булмаган материаллар предприятиесе» ҖЧҖ. Ямаш авыл җирлеге - ПГС карьерасы | Эшкәртү | | + | |

2.1 нче таблицаның 15 пунктын 16 пункт дип санарга

2.2. таблицага «Агросәнәгать комплексы чаралары исемлеге» яңа юл өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Н.Е. Токарликов исемендәге сөт-товар фермасы АҖ, Рус Акташы авыл җирлеге, Акташ станциясеннән төньяк-көнчыгыштарак | яңа төзелеш | | + | |

2.17. таблицага «Транспорт-коммуникация инфраструктурасын үстерү чаралары исемлеге» өстәргә:

«Җирле әһәмияттәге автомобиль юллары» бүлегендә яңа пункт:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 48 | Колшәрип тимер- юл станциясенә юл, («Әлмәт-Чупай» - Кичучат» - Колшәрип станциясе п.) | Әлмәт МР | төзе леш | V | * | 3,478 | | | | | | |

«Тимер юллар (федераль әһәмияттәге объектлар)» бүлегендә 48 пунктны 49 пункт дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле яңа «Тимер юллар (җирле әһәмияттәге объектлар)» бүлеге өстәргә:

| Тимер юллар (җирле әһәмияттәге объектлар | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 50 | Колшәрип станциясеннән тимер юл тупигы | Әлмәт МР | төзелеш | | | | * | 3,1 | | | |
| 51 | Әлмәт (Кәләй) станциясеннән тимер юл тупигы | Әлмәт МР | төзелеш | | | | * | 1 | | | |

«Региональ әһәмияттәге юл буе сервисы объектлары» бүлегендә 49 пунктны 52 нче пункт дип санарга.

1.3. Җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен тәкъдим ителгән җир кишәрлекләре чикләренең картасын яңа редакциядә бәян итәргә (1 нче кушымта).

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевкий вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматлар порталында (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне район Советеның икътисадый үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Закиров Ш.К.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль
районы Советының 2020 елның
23 июнендәге 379 нчы номерлы
карарына 1 нче кушымта




Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов